СОВЕТ МАЙДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МӘЙДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

05.03.2018 с. Майдан № 35-161

### Салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә җир салымы түләү буенча салым ташламалары бирү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгыннан ирекле саклау турында» 2011 елның 6 маендагы 100-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» 01.08.2011 № 48-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә таянып,

Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләренә җирнең кадастр бәясеннән 0,2 % күләмендә җир салымының киметелгән ставкасын куллану рәвешендә җир салымын түләү буенча салым ташламасын түбәндәгечә билгеләргә:

- янгыннан ирекле саклау буенча иҗтимагый берләшмәләргә;

-янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләренә һәм ирекле янгын сүндерүчеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән салым түләүчеләр өчен ташламалар эшкуарлык эшчәнлеге өчен файдаланылмый торган, ә берничә җир кишәрлеге (өлешләре) булган җир кишәрлекләренә карата бары тик бер җир кишәрлеге өчен генә бирелә дип билгеләргә";

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән салым түләүче-физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турында гариза үз сайлаулары буенча тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документларны тапшырырга хокуклы";

4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы

Мәйдан авыл җирлеге Советы рәисе В. В. Михеев